**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

11.03.2016 | № 130

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 1 апрелендә теркәлде, № 3271

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгында
Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык
хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның
чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның,
сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең
һәм дини берләшмәләрнең мактаулы
һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен
кабул итүе тәртибен раслау хакында

"Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка аерылып тору билгеләрен кабул итүе тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2015 елның 10 октябрендәге № 506 Указына, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасының аларга билгеләп куйю һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка аерылып тору билгеләрен кабул итүе тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2016 елның 12 гыйнварындагы № УП-5 Указына туры китереп, **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең, шул исәптән диниләренең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүенең кушымта итеп бирелүче тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә: Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларны һәм, алар белән хезмәт контрактлары төзегәндә, гражданнарны Тәртип белән таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2016 елның 11 мартындагы № 130 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның (алга таба – гражданлык хезмәткәре, Министрлык) чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнниләрдән гайре), бүләкләрен (алга таба – исемнәр, бүләкләр) кабул итүе процедурасын регламентлаштыра, әгәр әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына керсә.

2. Гражданлык хезмәткәре, исемнәр, бүләкләр алганда, Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының (алга таба – министр) рөхсәтен алырга бурычлы.

3. Исем, бүләк алган яисә аларны алачагы турында чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә, дини берләшмә тарафыннан хәбәр алган гражданлык хезмәткәре, тиндәшле рәвештә, исем, бүләк яки әлеге хәбәрнамәне алган көннән башлап өч эш көне эчендә, чит ил дәүләтенең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итәргә рөхсәт бирү турында

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә бу Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән үтенеч (алга таба – үтенеч) тапшыра.

4. Исем, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәткәре, өч эш көне эчендә, чит ил дәүләтенең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алудан баш тартуы турында дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә бу Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) тапшыра.

5. Министрның үтенечне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итүенә кадәр исемне, бүләкне алган гражданлык хезмәткәре, аларны алган көннән башлап өч эш көне эчендә, исем белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен Министрлыкның административ-хуҗалык бүлегенә җаваплы саклауга тапшыра. Бу вакытта бу Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

6. Эш буенча командировкасы вакытында гражданлык хезмәткәре исемне, бүләкне алган яки алардан баш тарткан очракта, үтенеч яки хәбәрнамә тапшыру срогы гражданлык хезмәткәре эш буенча командировкадан кайткан көннән башлап исәпләнә.

7. Аңа бәйле булмаган сәбәп аркасында гражданлык хезмәткәре үтенеч яки хәбәрнамә тапшыра алмаган, исем белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен бу Тәртипнең 3 - 5 пунктларында күрсәтелгән срокларда тапшыра алмаган очракта, ул үтенеч яки хәбәрнамәне, исем белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен андый сәбәп бетерелгәннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча тапшырырга бурычлы.

8. Үтенечне (хәбәрнамәне) теркәү ул кергән көнне дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан, бу Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән теркәү журналында башкарыла. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге үтенечне (хәбәрнамәне) ул теркәлгән көннән башлап ике эш көне үткәнче, министрга тапшыра.

9. Үтенечне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча министр кабул иткән карар турында дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, кара кабул ителгән көннән башлап ике эш көне эчендә, гражданлык хезмәткәренә хәбәр итә һәм үтенечнең (хәбәрнамәнең) билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсен аңа биреп, кул куйдыра. Үтенечнең (хәбәрнамәнең) министр резолюциясе салынган төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең "личное дело"сына куела.

10. Гражданлык хезмәткәренең бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенече министр тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта, Министрлыкның административ-хуҗалык бүлеге, 10 эш көне эчендә, исем белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен гражданлык хезмәткәренә тапшыра. Бу вакытта бу Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

11. Министр гражданлык хезмәткәренең бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенечен канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, Министрлыкның административ-хуҗалык бүлеге, 10 эш көне эчендә, исем белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның белән бирелүче документларның төп нөсхәләрен чит ил дәүләтенең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең тиешле органына җибәрүне тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

_______________________________

(Ф.И.О.)

_______________________________

(биләнүче вазыйфа)

_______________________________ дан

(Ф.И.О., телефон номеры)

Чит ил дәүләтенең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген кабул итәргә рөхсәт турында

**үтенеч**

Миңа ________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

______________________________________________________________

(нинди хезмәтләр өчен бирелгән һәм кем тарафыннан, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

______________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исем белән бирелүче документларны,

______________________________________________________________

бүләкне бирү көне һәм урыны)

кабул итәргә рөхсәт бирүне үтенәм.

Мактаулы яки махсус исем белән бирелүче документлар, бүләк һәм аның белән бирелүче документлар (кирәклесенең астына сызарга) _____________________

______________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

______________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исем, бүләк белән бирелүче документлар атамасы)

"___"_____________20__ел № _____ кабул итү-тапшыру акты буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ-хуҗалык бүлеге хезмәткәренә ________________________________________ тапшырылды.

(хезмәткәрнең Ф.И.О.)

"___"______________20__ел ____________ __________________________

(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

______________________________________

(Ф.И.О.)

______________________________________

(биләнүче вазыйфа)

__________________________________ дан

(Ф.И.О., телефон номеры)

Чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исеменнән, бүләгеннән баш тарту турында

**хәбәрнамә**

________________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

________________________________________________________________________

(нинди хезмәтләр өчен бирелгән һәм кем тарафыннан, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

_______________________ алудан баш тарту турында карар кабул итүемне җиткерәм.

"____" _________ 20 ____ел ____________ _ ____________________

(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибенә 3 нче кушымта

Кабул итү-тапшыру
**акты**

"____" ________ 20__ ел №___

Без, түбәндә кул куючылар, шул хакта акт төзедек:
________________________________________
(Ф.И.О., вазыйфасы)
тапшырды/кабул итте (кирәклесенең астына сызарга), ә
________________________________________ йөзендә
(Ф.И.О., вазыйфасы)
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне кабул итте/тапшырды:

| Т-п № | Атамасы | Саны (данә) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды: Кабул итте:

________ ____________________ ________ ____________________
(имза) (тулы имза) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибенә 4 нче кушымта

## Үтенечләрне (хәбәрнамәләрне) исәпкә алу

## ЖУРНАЛЫ

| Т-п № | Үтенечне (хәбәрнамәне) тапшырган гражданлык хезмәткәренең Ф.И.О. | Үтенечне (хәбәрнамәне) тапшырган гражданлык хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенечнең (хәбәрнамәнең) кергән көне | Бүләк, исем атамасы | Кабул итү-тапшыру акты (булганда) реквизитлары | Үтенечне (хәбәрнамәне) кабул итеп алган затның имзасы, Ф.И.О. | Үтенечне (хәбәрнамәне) тапшырган затның имзасы, Ф.И.О. | Министрның карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |